ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРОКАРАЗЕРИКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д.12,
с.Старый Каразерик, 423965

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КАРАЗИРЕК АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 12 йорт,
Иске Каразирек авылы, 423965

Тел.:(85593) 4-12-27, факс:4-12-27, e-mail: Skar.Utz@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№12 20.09.2023 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлегенең 2014 елның 3 декабрендәге 20 санлы карары белән расланган Ютазы муниципаль районының Иске Каразирек авыл җирлеге башкарма комитетында муниципаль хезмәткәр, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балалары чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2023 елның 26 гыйнварындагы «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында»гы 1-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Иске Каразирек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Иске Каразирек авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Иске Каразирек авыл җирлегенең 2014 елның 3 декабрендәге 20 санлы карары белән расланган Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлеге башкарма комитетында муниципаль хезмәткәрнең, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Кушымтаның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Муниципаль хезмәткәрләр үзләренең чыгымнары турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар) сатып алуга кагылышлы һәр алыш-биреш буенча чыгымнары турында, әгәр алыш-биреш суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренец) алыш-биреш башкарылганчыга кадәр соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артса, алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр тапшырырга тиеш. Белешмәләр билгеләнгән рәвештә белешмә рәвешендә тапшырыла (Тәртипкә 1 нче кушымта).».

1.2. Тәртипнең 7 өлешендәге 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян

итәргә:

«3) әлеге затның чыгымнарының, шулай ук аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чаралары, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар) сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча чыгымнарының туры килүен билгеләү.»

1.3. Тәртипнең 7 өлешендәге 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) аның чыгымнары турында, шулай ук аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталларындагы катнашу өлешләре, пайлар) сатып алуга кагылышлы һәр алыш-биреш буенча чыгымнары турында, әгәр алыш-биреш суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш башкарылганчы соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артса;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Иске Каразирек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгару юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасының Бердәм муниципаль берәмлекләре Порталы составында «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Иске Каразирек авыл җирлеге
башлыгы вазыйфаларын башкаручы Э.М.Минниярова